**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5014**
**07.09.2018**

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак бүлмәләрен наемга алу килешүе буенча торак бүлмә бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак бүлмәләрен наемга алу килешүе буенча торак бүлмә бирүгә мохтаҗлар дип тану максатында, Татарстан Республикасының «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын наемга алу килешүләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ санлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2018 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 10 121 сум 98 тиен;

2) гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 672 804 сум;
- ике кешелек гаилә өчен – 1 345 608 сум;
- өч кешелек гаилә өчен – 2 018 412 сум;
- дүрт кешелек гаилә өчен – 2 691 216 сум;
- биш кешелек гаилә өчен – 3 364 020 сум;
- алты кешелек гаилә өчен – 4 036 824 сум;
- җиде кешелек гаилә өчен – 4 709 628 сум;
- сигез кешелек гаилә өчен – 5 382 432 сум;
- тугыз кешелек гаилә өчен – 6 055 236 сум;
- ун кешелек гаилә өчен – 6 728 040 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин